

Мордовия Республикасы Матбугат vзәгендә журналистлар белән мошенниклыкның торле торләренә каршы тору ысуллары турында брифинг vтте.
Чараның спикерлары булып РМ буенча Эчке эшләр министрлыгының Жинаятьчеләрне эзләv идарәсе бvлеге житәкчесе урынбасары Андрей Батаенков һәм Россия Бан кының РМ буенча баш идарәсе Милли банк бvлекчәсенен куркынычсызлык бvлеге эксперты Александр Пет ров чыгыш ясады.       Тобәк эчке эшләр министрлыгы вәкиле республикада узган ел мошенниклар гамәлләреннән зыян кvрvчеләр саны, шулай ук китерелгән зыянның кvләме турында мәгълvмат китерде. 2025 елда республикада яшәvче 1 200дән артык кеше жинаятьчеләр корбаны булды. Алдау юлы белән кылынган акчаларны урлаудан килгән гомуми зыян 500 миллион сумга якын тәшкил иткән.
Андрей Батаенков гражданнарны таныш булмаган кешеләр белән телефоннан яки мессенджерларда аралашуда тәнкыйди фикерләv кvрсәтергә һәм чит реквизитларга акча кvчерv турында карар кабул итәргә ашыкмаска чакырды. Әнгәмәдәшләр нинди генә куркыныч нәтижәләр белән янамасын, аралашудан баш тартырга кирәклеген әйтте. Әгәр сvз финанс продуктларын ниндидер дискредитацияләv яки банк счетлары буенча законсыз операцияләр турында барса, вәзгыятьне ачыклау очен vзебезгә финанс оешмасына морәжәгать итәргә кирәк.
Эчке эшләр министрлыгының Жи наятьчеләрне эзләv идарәсе бvлеге житәкчесе урынбасары республика халкына карарлар кабул иткәнче туганнарына һәм якыннарына, дусларына һәм танышларына гадәти булмаган хәлләр турында сойләргә киңәш итте. Читтән карау еш кына хәлне аек бәяләргә һәм акчаларны югалтуны булдырмый калырга ярдәм итә. Россия Банкының РМ буенча баш идарәсе Милли банк бvлекчәсенен куркынычсызлык бv-леге эксперты Александр Петров мошенникларны танып белергә һәм аларның хәйләләренә эләкмәскә ярдәм итәчәк ысуллар турында сойләде. Иң куркынычсыз стратегия - гомумән әнгәмәгә кермәv. Трубканы шунда ук кую яхшырак. Беркайчан да уяулыгыгызны югалтмагыз: vзегезгә һәм якыннарыгызга сакчылрак һәм игътибарлырак булыгыз.
Шулай ук ул финанс хезмәтләрен кулланучыларны финанс компаниясен сайлаганда сак булырга һәм беркайчан да легаль булмаган кешеләр белән хезмәттәшлек итмәскә чакырды. Мисал очен, Александр Петров DigiCash кебек проект белән бәйле куркынычлар турында кисәтте. Россия Банкы проект эшчәнлегендә легаль булмаган кредитор билгелә-рен ачыклады, аның турындагы мәгълvмат регуляторның кисәтv исемлегенә кертелде. Проектны оештыручылар заем алырга тәкъдим итә һәм шундук Россия территориясен-дә финанс хезмәтләрен кvрсәтvгә Россия Банкының рохсәте булмаган килеш хокукый кырдан тыш эш итvләрен кисәтә. Клиентлар белән аралашу мессенджерлар һәм социаль челтәрләрдәге битләр аша алып барыла. Шул ук каналлар аша киләчәктә шәхси мәгълvмат жыю да vткәрелә. Мордовия Республикасы буенча Милли банк бvлеге эксперты искәрткәнчә, финанс оешмасы легальме яки юкмы икәнен Россия Банкы сайтында тикшерергә момкин.

**Наилә НАСЫРОВА**